| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**2025 елда Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Бердәм эшчәнлек» халыкара конференциясен уздыру турында**

Дәүләт хакимияте органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең ак барсның популяциясен саклау һәм торгызу буенча бердәм эшчәнлеген тәэмин итү максатында **карар бирәм:**

1. 2025 елның 13 мартыннан 15 мартына кадәр Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Бердәм эшчәнлек» халыкара конференциясен уздырырга.

2. 2025 елда Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Бердәм эшчәнлек» халыкара конференциясен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә.

3. 2025 елда Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Бердәм эшчәнлек» халыкара конференциясен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2025 елда Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Бердәм эшчәнлек» халыкара конференциясен әзерләүне һәм уздыруны оештыруны тәэмин итәргә, шулай ук әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 28 декабрь
№ 1035

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «28» декабрендәге
1035 номерлы Указына
1 нче кушымта

**2025 елда Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Бердәм эшчәнлек» халыкара конференциясен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2025 елда Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Бердәм эшчәнлек» халыкара конференциясен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба тиешенчә – Оештыру комитеты, Халыкара конференция) – дәүләт хакимияте органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Халыкара конференцияне әзерләгәндә һәм уздырганда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

II. Оештыру комитетының төп бурычлары

3. Оештыру комитетының төп бурычлары:

Халыкара конференцияне әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын эшләү һәм раслау;

Халыкара конференцияне үткәрүне әзерләүгә бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыру барышын анализлау, Халыкара конференцияне әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итү;

Оештыру комитеты кабул иткән карарларны гамәлгә ашыру барышында дәүләт хакимияте органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

Халыкара конференцияне әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын үтәүгә бәйле бурычларны хәл иткәндә дәүләт хакимияте органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген

оештыру.

4. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт хакимияте органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә;

билгеләнгән тәртиптә үз утырышларына дәүләт хакимияте органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен, аларның башка вәкилләрен һәм кызыксыну белдергән башка затларны чакырырга;

үз вәкилләрен Халыкара конференцияне әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашырга җибәрергә.

III. Оештыру комитеты составы

5. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәистәшләре, рәистәшләр урынбасары, Оештыру комитеты секретаре һәм аның башка әгъзалары керә, алар Оештыру комитеты эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

7. Оештыру комитеты рәистәшләре:

а) Оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итәләр, Оештыру комитеты утырышларында карала торган мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгелиләр;

б) Оештыру комитеты рәистәшләре урынбасары һәм әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазыйфаларны) бүләләр;

в) утырышларның көн тәртибен, уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгелиләр һәмраслыйлар;

г) Оештыру комитетының утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларына кул куялар.

8. Оештыру комитеты секретаре:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Оештыру комитеты әгъзаларына утырышны уздыру көненә кадәр кимендә биш көн кала утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

в) Оештыру комитетының утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерли.

9. Оештыру комитеты әгъзалары:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Оештыру комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча фикер алышуга тәкъдимнәр бирә;

в) Оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

## IV. Оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

10. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

11. Оештыру комитеты утырышларын рәистәшләр яисә рәистәшләрнең берсе алып бара.

12. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, эш алып барырга хокуклы дип санала. Оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Оештыру комитеты утырышында көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тавыш бирү йомгаклары буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәистәшләр яисә рәистәшләрнең берсе кул куя.

13. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар кызыксынган дәүләт хакимияте органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, кызыксынган башка затларга эшчәнлек алып барганда куллану өчен җиткерелә.

## V. Оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

14. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итүне «Ирбис» ак барсны өйрәнү һәм саклау үзәге» төбәкара ассоциациясе белән хезмәттәшлектә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы башкара.

---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның « 28 » декабрендәге
1035 номерлы Указына
2 нче кушымта

**2025 елда Казан шәһәрендә «Дөнья күләмендә ак барсны өйрәнү һәм саклау. Тырышлыкны берләштерү» халыкара конференциясен әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты**
**составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Рәисе, оештыру комитеты рәистәше |
| Узденов<br>Али Муссаевич | «Ирбис» ак барсны өйрәнү һәм саклау үзәге» төбәкара ассоциациясе гомуми җыены рәисе, оештыру комитеты рәистәше (килешү буенча) |
| Гафаров<br>Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, оештыру комитеты рәистәшләре урынбасары |
| Петрова<br>Дарья Владимировна | «Ирбис» ак барсны өйрәнү һәм саклау үзәге» төбәкара ассоциациясе директоры, оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |
| Әминов<br>Әнвәр Солтан улы | «Карым» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарма директоры (килешү буенча) |
| Әмирханов<br>Әмирхан Мөхәммәт улы | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәте җитәкчесе киңәшчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Вахитов<br>Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Мәганов<br>Наил Өлфәт улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мөхәммәтова<br>Абидәт Мөхәммәтсәлам кызы | Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының Табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек департаменты директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Маканова<br>Ирина Юрьевна | Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының Аеруча саклана торган табигать территорияләрен үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәте һәм җайга салу департаменты директоры (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Шадриков<br>Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |